Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№4 (728) 25 февраль 2021 ел (1442, Рәҗәб) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ЯРДӘМЧЕЛЛЕК һӘМ АДӘМЧЕЛЕК



Халыкларга ярдәм бирү фәкать кирәкле вакытларына гына махсус булып, башка вакытта һичкем-һичкем өстенә салынып торуы, ни гакылча, ни шәригатьчә дөрес түгелдер. Шуңа нигезләнеп, адәмнәр өстенә салынмагыз, аларның малларына өметләнмәгез, бәлки үз ризыкларыгызны үзегез эзләгез, үзегез өчен үзегез йөрегез! Адәмнәргә катнашмыйча бер читтә тормагыз вә яки кем очрады исә аңа катышып, дуслык күрсәтмәгез, бәлки һәр эштә гаделлек белән хөр фикерле, дөрес сүзле, баһадир, эчегез вә тышыгыз бер рәвешле булыгыз! Ант итүләрегезне саклагыз, вәгъдәләрегезне җиренә җиткереп, дусларыгызга тугрылыклы булыгыз, халыкларның кайгы вә шатлыкларын уртаклашыгыз. Үзегез сөймәгән нәрсәләрне аларга да сөйдермәгез, әгәр дә мөгамәләгез бу нигезгә нигезләнер булса, арада бердәмлек нык булыр, дуслык таралыр. Халык файдасы вә хак җирләргә ярдәм юлында үткән вакытларны әрәм ителгән вакыт дип санамагыз. Чөнки башкаларны сөю вә аларга ярдәм бирү вә аларның җитешмәгән җирләрен җитештерү — бөеклек вә адәмчелек билгеседер.

**Риза ФӘХРЕДДИН** *(”Әхлак гыйлеме”ннән)*

## “ИЗГЕ КОРЪӘН ДӨНЬЯСЫНДА”



Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында, сирәк туплнамалар галереясендә Татарстан мөфтие һәм нәзарәт белән берлектә оештырылган Коръәннәр күргәзмәсе ачылды. Күргәзмә Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап, Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан Ислам кабул итүнең 1100 еллыгына әзерлек уңаеннан оештырылды. Ул шәһәрнең тарихи өлешендә – элек Декоратив-гамәли сәнгать музей-остаханәсе урнашкан бинада урын алды. “Изге Коръән дөньясында” күргәзмәсе төп ике шәхси коллекциядән тупланды – күпчелек Коръәннәр Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Коръәннең кульязма вариантларын күчереп язучы, реставратор Дамир Әхмәтгалиев тарафыннан җыелды. Биредә VII гасырдан алып XXI гасырга кадәр таралган Коръәннәрне һәм Коръән битләренең күчермәләрен күрергә мөмкин.

Әлеге чара Казанның Галиев мәчете мөәзине Сәидкамал хәзрәт башкаруында Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Аннары Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры Гөлзада Руденко сүз алды һәм күргәзмәнең барлыкка килү тарихы белән таныштырды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышында, хәзерге вакытта Рәҗәб ае баруын ассызыклап, озакламый Коръән иңгән ай – Рамазан ае җитүен әйтеп үтте. Музей-тыюлыкта узучы күргәзмәгә төрле җирлекләрдә басылган 32 факсимильле һәм басма Коръәннәрне, тулы бер Коръән сыйган зур плакатны тапшырды. Шунысын да әйтергә кирәк, Нәзарәт тарафыннан нәшер ителгән Коръән китаплары Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы фондында калачак. Күргәзмә алты ай дәвамында эшләячәк.

*(ТР МДН хәбәрләреннән)*

## ЧАЛЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

17 февраль көнне Чаллы шәһәре мөхтәсибәтенең чираттагы җыелышы үтте. Аның беренче өлешендә Үзәкләштерелгән Дини оешма Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең 12 апрель көнне узачак VIII чираттагы съездына Чаллы мөхтәсибәтеннән баручы делегатлар исемлеге билгеләнде. Мәҗлеснең икенче темасы буларак ТР МДН тарафыннан республикабыз мәчетләре һәм имам-хатыйблары өчен үткәрелгән “Изге әманәт” бәйгесе нигезләмәсе белән танышу алынды. Имамнар җыелышының соңгы өлешендә балаларның республика күләмендә Чаллыда язгы каникуллар чорында үтә торган 25 нче традицион Коръән уку бәйгесе һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән XII Рәсәйкүләм турниры турында сүз алып барылды. Аның нәтиҗәсе буларак, моңа кадәр март аеның икенче яртысында үткәрелеп килгән Коръән уку бәйгесен кичектереп торырга, ә ТР МДН кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән XII Рәсәйкүләм турнирын 4 апрельдә үткәрергә дигән карар кабул ителде. Имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт Гайфуллин имам-хатыйбларга һәр мәчеткә ел дәверендә үткәреләчәк берәр бәйге билгеләргә кушты. Имамнар җыелышы дога кылу белән тәмамланды.

***

Чаллы мөхтәсибәте шәһәр халкын һәм кунакларын 28 февраль көнне Яр буе паркына гаилә белән чаңгы шуарга чакыра. Теркәлү иртәнге 9:00 сәгатьтә, ярышлар һәм уеннар 9:30да үткәрелә башлый, ачылыш һәм гомуми ярыш 10:00 сәгатьтә, 10:30да - нәтиҗәләр ясау. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылачак. Үзегез белән җылыныр өчен кайнар чәй һәм күтәренке кәеф алып килүегез сорала. Чара ҮДО ТР МДН Чаллы шәһәре мөхтәсибәте тарафыннан сәламәт яшәү рәвеше, спорт белән даими шөгыльләнү һәм чаңгыда шууны пропагандалау максатыннан инде берничә ел рәттән үткәрелә.

**Нияз ГАЗИЗОВ**

# СӨЛӘЙМАН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ

Дауд галәйһиссәламнең улы Сөләйман галәйһиссәлам... Исраиллеләр уларының бу бөек пәйгамбәре Аллаһы тарафыннан сайлап алынган һәм Аның күпләгән рәхмәтләре - хикмәт, гаделлек, байлык һәм тиңсез хакимлек белән бүләкләнгән. Сөләйман галәйһиссәлам җирдәге барлык җан ияләренең телләрен һәм башкаларның аңнарына сыймаган бик күп серләрне белгән. Аллаһы тарафыннан бирелгән белемнәрне һәм сәләтләрне ул кешеләрнең яшәешләрен яхшырту һәм аларны хак дин юлына чакыру өчен файдаланган. Сөләйманның хак патшалыгы турында дан-шөһрәт бар дөньяга тарала һәм ул әлегә кадәр яши бирә... Кәлам Шәриф битләрендә.

Бервакыт Сөләйманның әтисенә – патша һәм пәйгамбәр Дауд галәйһиссәламгә килеп туган бәхәсләрендә гадел карар чыгару үтенече белән ике кеше килә. Берсенең сарыклары икенче бер кардәшенең йөзем бакчасына кереп, бер сабагын да калдырмыйча барлык чәчүлекләрне ашап бетерә. Дауд галәйһиссәлам аларга түбәндәге карар чыгаруы турында хәбәр бирә:

– Һәлак булган үсентеләр хисабына барлык сарыклар да бакча хуҗасына бирелергә тиеш.

Дауд галәйһиссәламнән чыккач, әлеге ике кеше Сөләйман галәйһиссәламне очрата һәм аңа барысын да сөйләп бирә. Әмма, аларны тыңлап, Сөләйман галәйһиссәлам болай ди:

– Әгәр мин сезнең мәсьәләне караган булсам, башка карар кабул иткән булыр идем.

Сөләйман галәйһиссәламнең сүзләре кичекмәстән Дауд галәйһиссәламгә билгеле була. Ул үзенә улын чакырып ала һәм ике кешенең бәхәсе буенча аның фикерен сорый. Сөләйман галәйһиссәлам җавап бирә:

– Сарыклар беркадәр вакытка бакча хуҗасына бирелергә тиеш. Ул чагында дөньяга килгән бәрәннәр, шулай ук сөт һәм йон аныкы булачак. Ә юкка чыгарылган бакча сарык хуҗасына бирелергә тиеш, кайчан да кайчан бакча элекке халәтенә килеп, җимеш бирә башлагач, ул хуҗасына кайтарылып бирелсен. Минем карашка, бу иң дөрес карар.

Улын тыңлап, Дауд галәйһиссәлам аның белән килешә һәм моны иң дөрес, гадел карар дип таный.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: **«Без аны Сөләйманга** (галәйһиссәлам) **аңлаткан идек. Һәрберенә дә хөкем** (пәйгамбәрлек) **һәм гыйлем биргән идек.** (Тәсбих белән мәшгуль булган вакытта) **Дауд** (галәйһиссәлам) **белән бергә тауларны һәм кошларны әмергә буйсындырдык ки, алар** (үз телләре белән Безне мактап) **тәсбих әйтәләр иде.** (Моның кебек эшләр сезгә бик кызык булса да,) **Без** (бөек пәйгамбәрләргә моның кебек могҗизаларны бирү эшен) **кылучылар булдык».** (“Әл-Әнбия” (Пәйгамбәрләр) сүрәсе, 79нчы аять).

Ике хатын-кыз яшәгән. Һәм бу хатын-кызларның һәрберсенең дә бер яшьләр тирәсендәге балалары булган. Бервакыт алар сабыйларын ияртеп һавада йөреп кайтырга чыгалар. Әмма яшь әниләр игътибарсызлык күрсәтәләр: бүре бер баланы эләктереп алып китә, һәм хатын-кызлар аны коткару өчен берни дә эшли алмыйлар. Хатын-кызлар арасында исән калган бала буенча бәхәс килеп чыга. Аларның берсе әйтә: “Бүре синең балаңны алып китте, ә бу минем бала”. Икенчесе әйтә: “Юк, бу минем бала, бүре синең балаңны алып китте”. Әлеге бәхәсне хәл итү өчен, алар, баланы алып, Дауд галәйһиссәламгә китә. Мәсьәлә бик катлаулы була, чөнки ике хатынның берсе дә юл бирергә теләми, һәм аларның сүзләрен раслаучы яки кире кагучы шаһитләр да булмый. Уйлап торгач, Дауд галәйһиссәлам яше буенча өлкәнрәк хатын-кызны яклап чыга, икенче хатын-кыз исә моның белән килешмичә барысын да Сөләйман галәйһиссәламгә сөйләп бирә. Пәйгамбәр аны тыңлап, җавап бирә:

– Әгәр сез чыгарылган карар белән килешмәсәгез, баланы урталайга чабыгыз. Ул сезнең икегезгә яртылаш эләксен – икегезгә да бала булыр.

Карарның коточкыч булуына да карамастан, өлкән хатын-кызны бу тәкъдим канәгатьләндерә, һәм ул баланы урталай ярырга рөхсәт бирә. Ә менә икенчесе, бала гомере өзелүдән куркып, үзенең дәгъваларыннан баш тарта: “Баланы ярмагыз. Мин баладан баш тартам, ул аңа булсын”.

Шуннан соң Сөләйман галәйһиссәлам өчен аларның кайсысының чыннан да яратучы әни булуы ачыктан-ачык аңлашыла. Ул баланы газаплaмас өчен, бала белән аерылышуны артыграк күргән әнигә биргән.

Хәзер инде чынлап торып баласын бүре алып киткән өлкән хатын, шушы кайгылы көннәр авыр мизгелләр булып күз алдына килеп басмасын дип, чит баладан котылырга әзер булуы да аңлашыла.

Исраиллеләрнең уллары арасында бер чибәр хатын-кыз яши. Ул ялгыз була һәм, күп вакытын гыйбадәт кылуга багышлап, бик тыйнак тормыш рәвеше алып бара. Бу җирлектә яшәүче дүрт билгеле кеше аңа гашыйк була һәм, хатын-кызның йөрәген яуларга тырышып, аңа ошау өчен төрле омтылышлар ясый. Тәкъва һәм акыллы булганлыктан, ул аларның барлык тәкъдимнәрен кире кага, ә тегеләре исә аны һаман да хурлыкка төшерү ягында була. Үзара сөйләшеп, аңа яла ягарга һәм бар дөньяга бу хатынның начар исемен чыгарырга килешеп, алар Дауд галәйһиссәламгә киләләр һәм аны хатын-кызның эт белән җенси мөнәсәбәттә булуына төшендермәкче булалар.

Дауд галәйһиссәламнең карары билгеле була – аны таш белән атып хөкем итәргә тиешләр иде. Әмма Сөләйман галәйһиссәлам әлеге дүрт кешенең ялган шаһитлек бирүләрендә шикләнеп, берничә егет каршында шушы судның тәртибен һәм Дауд галәйһиссәлам чыгарган хөкем карарын үзгәртергә уйлый. Ул да, мөхтәрәм атасы кебек үк, дүрт кешенең дәлилләрен тыңлый, әмма һәрберсен аерым сөйләтә. Ул егетләрнең берсен чакырып китерә һәм сорый: “Ул эт нинди төстә иде?” “Кара төстә”.

Аннары ул икенче егетне чакыра һәм аңа да шул ук сорауны бирә. Ул җавап бирә: “Эт җирән төстә иде”.

Өченчесе Сөләйман галәйһиссәламне этнең көрән төстә булуына, ә дүртенчесе – ак иде дип ышандырырга тырыша.

Шаһитләрнең капма-каршы сүзләре хатын-кызның гаепсез булуын ачыклый. Әлеге егетләрнең һәрберсенә яла ягулары өчен сиксән таяк сугып җәза бирелергә тиеш була. Бу сәхнәләштерелгән суд утырышы турында Дауд галәйһиссәлам ишетеп ала, ул шундук үзенә әлеге дүрт кешене чакыртып алырга боера һәм берәмләп алардан сорау ала. Ачыктан-ачык аңлашыла ки, алар бу хатын-кызга яла ягалар.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: «(Кылган бер гөнаһ сәбәпле) **Казанган нәрсәләре булмыйча, иманлы ирләрне һәм иманлы хатыннарны рәнҗеткән кешеләр өсләренә бик әшәке эш һәм ап-ачык гөнаһ йөклиләр».** (“Әл-Әхзәб” (Гаскәрләр) сүрәсе, 58нче аять).

Ә Аллаһы илчесе саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: “Кешене һәлак итүче җиде әйбердән ерагаегыз”. Сәхабәләр сораганнар: “Ий, Аллаһы илчесе! Бу җиде әйбер нәрсәләр соң?” Ул җавап биргән: “Аллаһыга тиңдәш кылу (ширек кату); сихерчелек; Аллаһы үтерергә тыйган кешене бер гаепсезгә үтерү; ятимнең малын ашау; риба; сугыш кырыннан качу; тәртипле хатын-кызга зина кылуда ялган гаеп ташлау”.

Сөләйман галәйһиссәлам, хаким булып, көн саен кешеләрнең гозерләрен тыңларга һәм аларның борчуларын хәл итәргә вакыт таба. Бервакыт, мохтаҗлар белән шундый әңгәмәләрнең берсендә, аңа бик тә мәртәбәле бер кеше керә. Сөләйман каршында үзенең проблемалары турында сөйләүче хәерченең утыруын күреп, ул аңа бик тә текәлеп карый башлый. Аның карашы шулкадәр көчле була ки, теге мескен куркуга кала һәм Сөләйман галәйһиссәламнән сорый:

– И, Аллаһының илчесе! Миңа явызлык белән караучы бу кеше кем?

Сөләйман галәйһиссәлам моның кунакка килгән Газраил галәйһиссәлам булуын әйтә. Әлеге кеше “Газраил” сүзен ишетү белән үк, агара һәм куркудан калтырый башлый. Коточкыч халәттә һәм дулкынланып ул Сөләйман галәйһиссәламгә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

– И, Аллаһының илчесе! Мин Газраил галәйһиссәламнең миңа явызлык белән каравын күрдем. Ул мине карашы белән көлгә әйләндерергә әзер иде. Аллаһы Тәгалә сиңа шундый хакимлек биргән ки, Ул сиңа хайваннарны һәм кошларны, шулай ук җилне һәм ташларны буйсындырган. Синнән сорыймын ки, җилгә әмер биреп, ул мине моннан еракка, Һиндстанга алып китсә иде. Бу урыннан еракка китеп, мин Газраил галәйһиссәламнең явызлыгыннан имин булырмын.

Сөләйман галәйһиссәлам бу кешене кызгана һәм аны Һиндстанга күчерү өчен җилгә әмер бирә. Җил исә, әмергә буйсынып, аны эләктереп ала да, ерактагы Һиндстан тавына илтеп ташлый.

Аннары Сөләйман галәйһиссәлам Газраил галәйһиссәламгә әйтә:

– И, Газраил! Ни өчен син миңа килгән кешегә шулкадәр текәлеп карадың? Нигә син аны куркыттың?

Газраил галәйһиссәлам җавап бирә:

– И, Аллаһының илчесе! Мин бу кешегә явызлык белән карамадым. Мин ул кешегә гаҗәпләнү белән карадым. Мине шунысы гаҗәпләндерде: ул монда, ә Аллаһы Тәгалә бу кешенең җанын миңа Һиндстанда алырга боерды. Мин уйга калдым: “Ничек соң алай була ала, мин әмерне үти алыр өчен, кыска гына вакыт аралыгында бу кеше ничек Һиндстанда була алачак?” Ул синнән җилгә әмер биреп Һиндстанга илтүен сорагач, миңа барысы да аңлашылды инде.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: **«... Вакытлары җиткәч, аны бер сәгатькә генә дә артка да, алга дә күчерә алмаслар».** (“Ән-Нәхл” (Бал кортлары) сүрәсе, 61нче аять).

Сөләйман галәйһиссәлам җил һәм җен белән идарә иткән, шулай ук бөҗәкләрнең, кошларның һәм хайваннарның телен аңлаган. Бервакыт кырмыска белән сөйләшеп, Сөләйман галәйһиссәлам аннан елга никадәр азык кирәк булуы турында сорый. Кырмыска әйтә: “Мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм”. Әлеге сүзләрнең дөреслегенә ышану өчен, Сөләйман галәйһиссәлам бер пыяла савытка бодай орлыгын һәм кырмысканы сала да капкачын ябып куя. Бер ел узгач, ул банканы ача һәм кырмысканың бары ярты орлыкны гына ашап бетергәнен күрә, ул аның икенче яртысын калдыра. Шул чагында Сөләйман галәйһиссәлам кырмыскага алдагы сөйләшү турында искә төшерә: “Син елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм дигән идең. Әмма мин күрәм ки, син бары яртысын гына ашагансың”.

*(Ахыры газетаның 3 нче битендә)*_

**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
*Татарстан Республикасы мөфтие*

*СОРАУ-ҖАВАП*

# ҖОМГА НАМАЗЫНА СОҢГА КАЛСАҢ...

**Сорау**. Әссәламү галәйкүм! Җомга намазына дип мәчеткә килеп кергәндә, имам әттәхият укый иде. Бу урында имамга кушылган кеше барыбер өйлә намазын укырга тиеш дигән фикерне ишеткәнем бар иде. Шушы сорауны ачыклагыз әле.

**Җавап**. Үә галәйкүм әссәлам! Хәнәфи мәзһәбендә мөселман, җомга намазы фарызының имам сәлам бирә башлаганчы кайсы өлешенә килеп кушылуына карамастан, аны, ике рәкәгать җомга намазы итеп, үзлегеннән тәмамлый. Ибн Нәҗәйм (рахимәхуллаһ) "Әл-Әшбәх вән-Нәзаир" китабында болай ди: "Әгәр имам бер намазны укый икән, аңа ияреп икенче намазны уку ярамый. Бу мәсьәләгә карата Имам Мөхәммәдтән кала мәзһәб галимнәре уртак фикердә тора. Имам Мөхәммәд фикеренчә, әгәр кеше җомга намазының тәшәһһүд яисә сәҗдә сәху өлешенә генә килеп кушыла икән, ул намазны дүрт рәкәгатьле өйлә намазы итеп укып бетерә. Әмма бу фикер буенча фәтва бирелми". Безнең мәзһәб буенча, кеше җомга намазының бер өлешенә өлгерми икән, намазын җомга намазы итеп тәмамлый. Искәрмәләрсез".

*(Диния нәзарәте фәтваларыннан)*

# СӨЛӘЙМАН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ

(Ахыры. Башы газетаның 2 нче битендә)

Моңа җавап итеп, кырмыска әйтә: "Әйе, барысы да дөрес, мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм. Әмма моңа кадәр миңа азыкны Аллаһы Тәгалә биргән иде, һәм мин Аның рәхмәтенә өмет багладым. Ә хәзер минем ризыгым көчсез кеше кулына калды – мин синең мәрхәмәтле булуыңа ышанмадым һәм бары ярты орлыкны гына ашадым, ә калган яртысын киләчәк көннәргә калдырдым".

Бу хакта Аллаһы Тәгалә менә ниләр әйтә: **«Җирдә Аллаһ ризык бирмәгән бер генә җан иясе дә юк. Ул аларның урнашкан урыннарын да,** (аналарының карыннарыннан алып, үлгәннәреннән соң дәфен ителгәнчегә кадәр) **сакланган урыннарын да белә.** (Бөтен җан ияләренең саны, ризыклары, урыннары, әҗәлләре – боларның) **һәммәсе дә ап-ачык** (Ләүхелмәхфүз исемле) **бер китапта** (язылган)**».** ("Һуд" сүрәсе, 6нчы аять).

Бервакыт Сөләйман галәйһиссәламнең илендә корылык һәм ачлык башлана. Дәүләт башлыгы буларак, ул үз халкы белән бергә яңгыр сорап Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәргә карар кыла. Җәмәгать белән дога кылырга чыгалар. Гыйбадәт кылу урынына бару юлында аның игътибарын бер кырмыска җәлеп итә. Шул кечкенә генә бөҗәк, аягын өскә күтәреп, аркасына ятып дога кыла. Тыңлап торганнан соң, Сөләйман галәйһиссәлам кырмысканың Аллаһыга ничек ялварганын ишетә. Кырмыска болай дип дога кыла: "Ий, Аллаһы! Син безне бар кылдың. Син бүләкләгән язмышта без Синең рәхмәтеңә мохтаҗбыз. Башкаларның җинаяте сәбәпле безне һәлак итмәвеңне үтенәм". Шул вакытта Җәбраил галәйһиссәлам килә һәм әлеге кырмысканың догасы кабул булуы турында хәбәр бирә. Шулчак Сөләйман галәйһиссәлам җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп, болай ди: "Кире кайтыгыз. Яңгыр килүен сорап тиешле дога кылынды инде. Бу кырмыска Аллаһыга мөрәҗәгать итте, һәм аның догасы кабул ителде".

Менә шулай, кеп-кечкенә кырмысканың бөек һәм ихлас догасы сәбәпле тулы бер халык ачлыктан котылуга ирешә. Хакыйкатьтә, Аллаһы безне бары тәкъвалыгыбыз һәм иман ныклыгы дәрәҗәсенә карап хөкем итә.

Сөләйман галәйһиссәлам һәм кырмыска белән тагын бер вакыйга пәйгамбәр үзенең зур гаскәре белән юлга чыкканда була. Юлда ул янә тагын кырмыскалар күче белән очраша, алар ару-талуны белми эшлиләр, кышка әзерләнәләр иде. Сөләйман галәйһиссәламнең армиясен күреп, ана-кырмыска команда бирә: "И, кырмыскалар! Юл бирегез һәм ояга кереп яшеренегез, Сөләйман галәйһиссәлам гаскәре сезне ялгыш таптап китмәсен". Сөләйман галәйһиссәлам ана-кырмысканың әмерен ерактан ук ишетеп елмая һәм, кырмыскалар ояларына кереп качырга өлгерсеннәр өчен, үзенең сугышчыларына да туктарга куша.

Фәхреддин әр-Рази үзенең тәфсирендә болай ди: "Кырмыскаларга ояларына керергә әмер бирелә. Ана-кырмыска нидән курка соң? Сөләйман галәйһиссәлам хакимиятенең санын, күплеген, зурлыгын күрә калсалар, эшче кырмыскалар Аллаһы аларны бүләкләгән нигъмәтләргә карата рәхмәтсез булуларыннан курка ул".

Бу вакыйга-хәл хәтта Коръәндә дә чагылыш таба: «(Шамның) **Кырмыскалар** (белән тулы бер) **үзәненә барып җиткәч,** (аларның хөкемдарлары булган) **бер ана кырмыска: "И, кырмыскалар! Ояларыгызга керегез! Сөләйман** (галәйһиссәлам) **һәм аның гаскәрләре сезне абайламыйча таптамасын!" – диде».** ("Ән-Нәмл" (Кырмыскалар) сүрәсе, 18 нче аять).

Кырмыска турындагы хикәяттә бер хаким иясе үзенең кул астындагыларга бөек хикмәт, ә икенче берсе чын мәгънәсендә миһербанлык үрнәге күрсәтә. Хәдистә әйтелгәнчә, Аллаһы илчесе саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: "Сез барыгыз да көтүчеләр һәм үз көтүегез өчен җавап тотасыз...". Ә сөннәт барлык заманнар өчен мәңгелек булып тора, һәм аңа һәр кеше, шул исәптән хөкемдарлар да үзенең гадел идарә итүе белән иярергә тиеш. Шул чагында алар Аллаһының һәм үз халыкларының ризалыгына лаек булачак. Бәрәкәтле идарәнең нигезе – үзеңнең кул астыңда эшләгән барлык кешеләрнең дәрәҗәсенә, байлыгына, диненә һәм милләтенә карамастан, зирәк һәм гадел булу дигән сүз. Ә халыкның бурычы – Аллаһы Тәгалә тарафыннан тәкъдир кылынган җитәкче артыннан бару. Карагыз, Сөләйман галәйһиссәлам нинди бөек хаким булган, шуңа аның даны мең еллар узгач та тынмый! Раббыбыз барлык дәүләт җитәкчеләрен һәм хакимнәрне гадел һәм киң күңелле кылса иде. Коръәндә әйтелгәнчә, хәтта бөҗәк тә хакимлек итүчеләрне якларга тырыша бит.

**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,** *Татарстан Республикасы мөфтие*

**ӘДӘБИ СҮЗ**

***Рәзинә МӨХИЯР***

### *ЗЕКЕР*

*Эч пошуга дәва – зекер,*

*Йөрәк янса, дәва – зекер,*

*Күңел төшсә, дәва – зекер,*

*Кайгы басса, дәва – зекер,*

*Сагыш сарса, дәва – зекер,*

*Сырхауга да дәва – зекер,*

*Зекер әйтсәң, килә фикер,*

*Иң кирәкле, яхшы фикер,*

*Ярдәм итә әйткән зекер.*

***ӘНИ СҮЗЕ***

# ТАРИХ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Минем баһадирларыма - улларыма хөрмәтле пәйгамбәрләребез, күңелебезгә бик якын булган сәхабәләребез, безләргә күп файда калдырган галимнәребез турында сөйләп, сеңдереп, тормышта аларның гамәлләрен кабатласыннар өчен сәбәп табарга тырышам мин. Шул мисалларның берсе - "Ухуд" сугышы вакыйгасы.

Тарихны кыскача искә төшереп китәм. Бәдер сугышында мөселманнар җиңү яулагач, мөшрикләрнең ачулары чыгып, алар янә һөҗүм ясарга булалар. Сугыш Ухуд тавы янында була. Мөселманнар укчыларны шул тауга куялар һәм сөекле Пәйгамбәребез кисәтеп куя: "Җиңүебезне күрсәгез дә урыныгызда калып торыгыз, беркая да китмәгез, китмәгез!"- ди. Шулай итеп сугыш башлана, мөселманнар өстен кала башлый, мөшрикләр артка чигә, укчыларның күбесе урыннарыннан "трофей" җыярга төшеп китәләр. Мөшрикләрнең ул вакытта әле ислам динен кабул итмәгән, әмма бик акыллы Халид ибн Валид сугыш техникасын бик белүчән була һәм Ухуд тавын әйләнеп узарга план кора. Нәтиҗәдә мөселман гаскәре ике яклап кысыла һәм, кызганычка, җиңеләләр...

Без дә, талдан ясаган укларны алып, дәү әтиебез, балаларым белән "сәхнә" оештырабыз. Сөбеханаллаһ, егетләрем кыза-кыза, тиргә бата-чума "Ухуд" сугышы вакыйгасын уйный. Әтиебез дә кушыла бит әле! Әле беребез явыз, беребез яхшы яки киресенчә...

Ә иң мөһиме - бер мизгелебез белән бүлешмәкче булам. Урамга чыккач, мин һәрвакыттагыча табигать белән хозурланып торган вакытта, ишетеп алам: балаларым кар тавына менеп, "укчылар, укчылар торыгыз", - дип кычкырышалар. Аннан соң бер-берсе белән роль бүлешәләр: кем явыз да кем яхшы. Миңа да кушылырга сорыйлар бит әле, ә мин бик теләп кушылып уйныйм баһадирларым белән. Шулай итеп ислам динебезнең тарихын өйрәнәбез! Темабызны аппликацияләр белән дә ныгытабыз... Егетләремнең- бәхетләремнең үзләре искә төшереп уйный башлаулары. Аллаһыбызга чиксез шөкерләрем, димәк, гамәлләребез һич бушка түгел!

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА,** *Чаллы шәһәре*

## ТЕЛНЕ, ДИННЕ САКЛЫЙМ ДИСӘҢ...



Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) «Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алу фарыз» диюе - син нинчә яшьтә булуыңа карамастан, намаз, тәһарәт, госел тәртипләрен, иман шартын, кырык фарызны белергә тиеш, дигән сүз. Белмисең икән - зур гөнаһ, үлгәнче өйрәнеп кал. Намаз укый белмәүченең белмәвенә риза булып йөрүе - исерекнең аракы эчеп йөрүе, кемнеңдер уен автоматы янында басып торуы кебек үк зур гөнаһ. Намаз укырга өйрәндең икән - биш вакыт намазыңны вакытында укырга тырыш, тәһәҗҗүдкә тор, намазыңны мәчеттә җәмәгать белән укы, балаларың, якыннарың, дусларың да укысын - вәгазьлә, өйрәт. Хәләл кәсеп белән тормышыңны алып бар, гаиләңне тәрбиялә, матур яшә. «Мөселманнар ничек матур яши!» дип сокланырлык булсын. Вакытың булган саен гыйлем ал. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Алар - милли тел, милли кием, милли гореф», - дигән. Бездә телне саклау да, гореф-гадәтне саклау да, үзебезнең киемнәребезне кию дә - динне саклау булып тора. Шулай булмаганда, без милләтебезне югалтабыз һәм икенче милләткә әйләнәбез, ә безнең илдә икенче милләтнең, күпчелек милләтнең дине башка. Бу очракта милләтебезне сакламыйча торып, динне саклап булмый.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,** *ТРның баш казые*

## НИКАХ ТУРЫНДА ХӘДИСЛӘР



* Никах ул – минем сөннәтем, һәм аннан баш тартучы кеше миннән баш тарта. (Бохари, Мөслим).

* Фәкыйрьлектән куркып өйләнмәүче кеше бездән (мөселманнардан) түгел. (Әбү Мансур).

* Әгәр кешегә яхшы холыклы, тәкъва тормыш иптәше бирелсә, ул иманның (диннең) яртысына ия булды. Шул кеше иманының икенче яртысында тәкъва булсын. (Әл-Хәким).

* Иң яхшы холыкка ия булган мөэмин иң камил иманга ия. Сезнең арагыздагы иң яхшы холыклы исә шул, кем үз хатынына яхшырак мөнәсәбәт күрсәтә. (Әт-Тирмизи).

* Иманлы ир үз иманлы хатынына нәфрәт белән карарга тиеш түгел: әгәр аңа хатынының ниндидер сыйфаты ошамый икән, ул аның шактый күп яхшы сыйфатлары булуын да онытмаска тиеш. (Әхмәд, Мөслим).

* Әгәр хатын үз иренә: "Сиңа Аллаһның рәхмәте булсын!" – дисә, аның гөнаһлары ярлыкана. (Мөслим).

* Әгәр кешегә шушы 4 нәрсә бирелсә, ул бу дөньяның һәм ахирәтнең иң яхшы нигъмәтләренә ия булачак: 1) шөкер кылучы йөрәк; 2) Аллаһны даими зикер кылучы (искә алучы) тел; 3) авырлыкларга чыдам булган тән; 4) хәләл җефетенә хыянәт итмәүче тормыш иптәше. (Бохари, Мөслим).

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН** *әзерләде*

## БУРЫЧ

**"Мин кешеләрне һәм җеннәрне бары тик Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым"** *("Зарият (Таратучы)" сүрәсе, 56 нчы аять).*

Шулай булгач, кеше яратылуның мәгънәсе – аның Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышануында һәм Аңа гыйбадәт кылуында. Кеше гыйбадәт кылу өчен яратылган. Гыйбадәт кылу кешенең бурычы булып тора. Кеше гыйбадәт кылган очракта гына кеше булып кала. Әгәр дә үз бурычын үтәми икән, ул үзенең төп кыйммәтен югалта һәм кеше булу бәхетеннән мәхрүм итела.

*("Ислам нуры" аккаунтыннан)*

***Балалар өчен***

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ



Ерганактан кар сулары
Челтерәп аккан көйгә
Кушылып йөзә кәгазьдән
Ясаган кораб-көймә.
Үскәч әле үзем дә мин
Чыгармын сәяхәткә
Диңгезләргә, чит илләргә...
Һәм Мәккәгә, әлбәттә!

Журналлар күп, минем өчен
"Тылсымлы куллар" килә.
Мавыктырып, кызыктырып,
Бик күп дәресләр бирә.
Иман сабаклары да бар
Ул кызыклы журналда.
Кисү-тегү, аш әзерләү...
Эш табыла кулларга.




***Саулыгым-байлыгым***

## ПЕТРУШКА



Гастрит борчыганда, 3 чәй кашыгы вакланган петрушка тамырын, 1 стакан кайнар суга салып, 10 сәгать төнәтәләр. Ашарга ярты сәгать кала көнгә 4 мәртәбә 1әр аш кашыгы эчәләр. Гемоглобин түбән икән, петрушка яфрагы белән тамырын шул килеш ашыйлар. Пиелонефрит диагнозы куелганда, 100 г петрушка тамырын, 1 литр кайнар суга салып, 1 сәгать төнәтәләр. Икегә бүлеп, көн дәвамында эчәләр. Атна-ун көннән уңай якка үзгәреш сизелергә тиеш. Бавыр белән үт куыгында таш булганда, 20 г вакланган петрушка яфрагы белән тамырын 1 стакан кайнар суда 1 сәгать төнәтәләр. Ашарга ярты сәгать кала көнгә 3 мәртәбә 1/3әр стакан эчәләр. Шешенгәндә, кич 1 стакан вакланган петрушка яфрагы белән тамырын 2 стакан кайнар суга салып калдыралар. Иртән сөзеп, уртача зурлыктагы 1 лимон согы өстиләр. Көнгә 5 мәртәбә 1әр аш кашыгы эчәләр. 2 көннән 3 көнлек тәнәфес ясыйлар да дәвалануны дәвам итәләр. Атеросклероз авыруы булганда көн саен яшел петрушка ашарга киңәш ителә.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 850**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 25 февраль 16 сәг.**
**фактта 25 февраль 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**